СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

## КАРАРЫ

**от 31 октябрь 2019 г.** **№3**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында Түбән Мәтәскә авылы, Үзәк урам, 22 йорт, Түбән Мәтәскә авыл клубы адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 12 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында Түбән Мәтәскә авылы, Яшьләр урамы, 11 йорт, Түбән Мәтәскә урта гомуми белем бирү мәктәбе адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 12 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Үзәк, Тынычлык, Киров, Мәктәп, Татарстан урамында яшәүчеләр

2нче этап: Комсомол, Тукай, Түбән, Арчабаш, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан, Бөек Ватан сугышында катнашканнардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау;

Түбән Мәтәскә авылы: Түбән урам-30м; Яшьләр урамыннан Тукай урамына кадәрге тыкрык-100м; Тынычлык урамы-100м; Татарстан урамы-50 м.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Түбән Мәтәскә авылында кече архитектура формаларын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү;

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

Түбән Мәтәскә авылында скважина өчен насос сатып алу, 1 данә;

Түбән Мәтәскә авылында Үзәк урам буенча су белән тәэмин итү системасы суүткәргечләрен алыштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай урамы, 2 йорт; ТР, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12а йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов